КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 март г.Казань № 157

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен раслау турында» 2022 ел, 14 ноябрь, 1208 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен раслау турында» 2022 ел, 14 ноябрь, 1208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 11 февраль, 139 нчы; 2023 ел, 14 июнь, 718 нче; 2023 ел, 28 ноябрь, 1523 нче; 2023 ел, 5 декабрь, 1558 нче; 2023 ел, 20 декабрь, 1650 нче; 2024 ел, 4 сентябрь, 729 нчы; 2024 ел, 7 октябрь, 866 нчы; 2025 ел, 10 февраль, 65 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясенең III бүлегендәге

3.5 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләрнең хезмәт белән тәэмин ителүенә булышлык күрсәтеп тору системасын анализлау

Аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләр дискриминациягә һәм социаль стигматизациягә еш дучар булалар. Аутизм спектрындагы бозылышлары белән интеллектуаль бозылышлар бергә туры килгән очракта, тигезсезлек ихтималы тагы да арта. Күп кенә инвалидлар эшли алалар һәм эшләргә телиләр, бу аларның психик һәм физик сәламәтлеге өчен мөһим булып тора, үзләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына гына түгел, ә тулаем бизнеска һәм җәмгыятькә дә сизелерлек файда китерә алалар. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның $20^1$ статьясында социаль мәшгульлек төшенчәсенә закон нигезендә билгеләмә бирелгән, ул хезмәт эшчәнлегенә сәләте шактый дәрәҗәдә чикле булуга бәйле рәвештә халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә эш белән тәэмин ителмәгән һәм башка затлар ярдәмендә генә катлаулы булмаган (гади) эшчәнле төрләрен гамәлгә ашырырга сәләтле инвалидлар эшчәнлеге буларак билгеләнгән. Инвалидларның социаль мәшгульлеге социаль адаптацияләүгә һәм инвалидларны җәмгыять тормышына җәлеп итүгә юнәлтелгән.

Шулай ук киләчәктә эш эзләүчеләрне Татарстан Республикасындагы заманча, җәмгыять тарафыннан таләп ителә торган һәм конкурентлыкка сәләтле һөнәрләр белән үз вакытында таныштыру хисабына һөнәри юнәлеш бирү системасын камилләштерергә кирәк. Социаль күнекмәләрне һәм хезмәткә мотивацияләрне үстерү аеруча мөһим булып тора. Һөнәри юнәлеш бирү максаты белән экскурсияләр уздыру, стажировкалар оештыру һ.б. өчен эш бирүчеләрне хезмәттәшлеккә җәлеп итеп, өлкән сыйныф укучыларын һөнәрнең киң спектры белән таныштырырга.

Аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләрне эшкә урнаштырганда барлыкка килгән кыенлыкларны бетерү максатларында, инвалид кешеләр тормышы һәм аларның мөмкинлекләре турында - җәмгыятьнең хәбәрдарлыгын арттыру буенча даими мәгълүмат кампанияләрен уздырырга, шулай ук эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтеп тору, социаль мәшгульлек буенча хезмәтләр күрсәтүче коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашырырга кирәк.

Шуңа бәйле рәвештә аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь - бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыру, аларның социаль тәэмин ителеше максатларында түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган балаларны тәрбияләүче ата-аналарны эшкә урнаштыруда ярдәм итү чараларын (шул исәптән эш белән тәэмин ителешнең үзгәрә торган формаларын кулланып) гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт

учреждениесе белгечләрен, алар өчен кирәкле вакансияләр, эшкә урнашу урыннарын сайлаганда, аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь - бозылышлары булган кешеләр белән үзара хезмәттәшлек итәргә өйрәтү;

аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләрне эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтеп торуны оештыру чараларын гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү;

аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләрнең социаль мәшгульлеген оештыру чараларын гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү.»;

әлеге карар белән расланган 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплекслы булышлык күрсәтеп тору концепциясен тормышка ашыру чаралары планында:

5 бүлектә:

5.3 пунктның 5.3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.3.1. | инвалид балалар | | | | - | 20 | 30 | 40 | 40 | - | агымдагы финанслау | 4 900,0 | 8 500,0 | 8 500,0 | Татарстан Республикасы бюджеты»; |

«5 нче бүлек буенча барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «5 нче бүлек буенча барлыгы | | | | | | | | | 0,0 | 1 000,0 | 9 900,0 | 13 500,0 | 13 500,0»; | |

6 бүлектә:
6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6.2. | Чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү: | ТР ХЭһСЯМ | 2022 – 2026 еллар | | | | | | | | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты»; |
| | 1) аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләрне эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтеп торуны оештыру буенча; | | | аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләрне эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтеп тору буенча хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын өлешчә финанс белән тәэмин итү | | | | | | агымдагы финанслау | 2 540,0 | 2 500,0 | - | - | |
| | 2) аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләрнең социаль мәшгульлеге буенча | | | аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләрнең социаль мәшгульлеге буенча хезмәт күрсәтүчеләр белән тәэмин итүчеләрнең чыгымнарын өлешчә финанслар белән тәэмин итү | | | | | | - | - | - | 1 400,0 | 1 400,0 | |

«6 нче бүлек буенча барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «6 нче бүлек буенча барлыгы | | | | | | | | | 0,0 | 2 540,0 | 2 500,0 | 1 400,0 | 1 400,0 | |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 19 июнь, 727 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 19 июнь, 727 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 24 февраль, 92 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2026 елларда «Аутизм спектрындагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган затларны эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне һәм эшкә урнашкан чорда аларга булышлык күрсәтеп торуны оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 19 июнь, 727 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 30 декабрь, 1249 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин